| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча комиссия составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча комиссия турында» 2016 елның 26 декабрендәге ПУ-1229 номерлы Указы белән расланган (Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 10 мартындагы ПУ-209 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2017 елның 7 сентябрендәге ПУ-800 номерлы һәм 2018 елның 9 февралендәге ПУ-152 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча комиссия (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан А.А. Здуновны чыгарырга;

б) Комиссия составына Габделганиев Фәрит Солтан улын – Татарстан Республикасы икътисад министрын кертергә, аны Комиссия секретаре итеп расларга;

в) Комиссия әгъзасы А.А. Корбановның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Сатып алулар өлкәсендә халыкара консалтинг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 26 май
№ ПУ-392